**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы № 41-20 3 октябрь 2016 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авылы җирлеге биләмәсендә үзарасалым җыю һәм куллану буенча, җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Туйкә авыл җирлеге Уставының 12 маддәсе, Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 16 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Туйкә авыл җирлеге Советының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 40-19 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Туйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Туйкә авыл җирлеге биләмәсендә үзарасалым җыю һәм куллану буенча 2016 елның 20 ноябрь көнне референдум үткәрергә.

2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Туйкә авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2017 елда 500 сум күләмендә үзарасалым җыю белән килешәсезме. Үзарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, игътибар үзәгендә тоту (асфальт юлларны ремонтлау)- 20 мең сум;

2) авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, игътибар үзәгендә тоту (юлларга таш ташытып, җәйдерү)- 20 мең сум;

3) авыл эчендәге юлларны кышкы чистарту- 14 мең сум;

4) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (Туйкә, Камышлы Күл авылларының су линияләрен ремонтлау)- 40 мең сум;

5) ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту ( Туйкә авылы зиратының ритуаль йортын ремонтлау, Карамалы-Елга авылы зиратының коймасын алыштыру)- 50 мең сум;

6) җирлек территориясендә массакүләм физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар булдыру (спорт комплексы сатып алу, спорт мәйданчыгына койма тоту)- 53,5 мең сум.

ӘЙЕ ЮК”

3.Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.

4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис Закирова Р.Р.